“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе”
дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе

Педагогик
киңәшмә утырышында каралды
“29”август 2022 ел. №1
Интернат мәктәбе директоры
_______________Л.Р.Мартынова
Боерык белән кертелде №98-0
“ 31 ” 08 2022 ел

**5нче КОРРЕКЦИЯ** сыйныфы өчен
**туган (татар) теленнән һәм әдәбияттан уку предметы буенча**
**эш программасы**
Атнага **0,5** сәгать**,** елга **17_** сәгать

Төзүчесе:
**татар теле һәм әдәбият укытучысы Мөхәммәтҗанова Л.Ф.**

Килешенгән:
Директор урынбасары________И.Б.Шарифуллина

МБ утырышында каралды, беркетмә№1 “26 ”август 2022 ел
МБ җитәкчесе ___________М.Г.Шәрипова

Әлмәт 2022 ел

**Уку предметы буенча 5нче сыйныфта туган (татар) теленең эш программасына аңлатмалы язу**

**Эш программасының статусы.**

1. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (21.12.2012, №273-ФЗ)
2. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы Законы (25.10.1991, №1807-1, ред.12.03.2014)
3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен ФГОС нигезендә башлангыч гомуми белем бирү буенча җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы.
4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Инвалид балаларны өйдә тәрбияләү һәм укыту тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында" 16.06. 2008 ел, 401 нче карары.
5. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (22.07.2013, № 68-ЗРТ)
6. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (8.07.1992, №1560-XII; ред. 12.06.2014№53-ЗРТ)
7. Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы(1 — 11 нче сыйныфлар) /Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан:2018
8. Әлмәт интернат мәктәбендә дисциплина, предмет, уку курсларының эш программалары раслануы, эшләү тәртибе, структура нигезләмәсе 31.08.22 № 98-О.
9. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына программасы.
10. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына базислы уку-укыту планы.
11. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы турында нигезләмә (локальный акт).

Рус телле балаларга татар телен укытуның төп максаты: укучыларны татарча аралашырга өйрәтү,татар теленең орфоэпик, орфографик.лексик, грамматик нигезләрен системалы рәвештә үзләштерү,телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

1) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3) программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4) карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5) татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
6) татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкә¬сендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныш¬тыруны дәвам итү;
7) халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

**Уку елы башында белергә тиешле белемнәр:**

**Грамматик минимум:**

1. Башында, уртасында, ахырында бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
2. Лексик темаларга караган сыйфатларны артыклык, чагыштыру дәрәҗәләрендә кулланырга өйрәтү.
3. Боерык фигыльнең барлык-юклык формасы.
4. Кушма, парлы исемнәрне, мәгънәләрен аңлап, дөрес кулланырга ирешү.
5.Биредә, тегендә, монда, анда рәвешләрен сөйләмдә куллануны ныгыту.
6. Актив үзләштерелгән исемнәрнең тартым белән төрләнешен гамәли белүне ныгыту.
7. Фигыльнең өйрәнелгән заман формаларын аңлап аера белү һәм дөрес белдерү өчен кирәкле форманы сайлап кулланырга күнектерү.
8. Саннарның өйрәнелгән төркемчәләрен гамәли белүне ныгыту.
9. Зат алмашлыкларын килешләр белән төрләндереп, дөрес куллануга ирешү.

Берлек һәм күплек сандагы уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен, тартым һәм килеш белән төрләндереп, сөйләмдә куллану күнекмәләрен системалаштыру.

**Орфоэпик һәм орфографик минимум:**

1. Сузык һәм тартык авазлар. Татар теленең үзенчәлекле авазларын кабатлап тору.
2. Сүзләрнең иҗекләргә бүленешен истә тотып, сөйләм оештыра белү.
3. Сүзләрнең басымын билгеләү.
4. Сингармонизм законының асылын гамәли белү.
5. Хәрефләрне, сүзләрне, җөмләләрне каллиграфик дөрес итеп яза белүне камилләштерү.
6. Сүзләрнең грамматик мәгънәләрен үзгәртә торган мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны дөрес билгеләү күнекмәләрен булдыру.
7. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.
8. Орфоэпик һәм орфографик яктан сөйләмне оештыру эшен тирәнәйтү.

**Тыңлап аңлау:**

1. Җанлы сөйләмне тыңлап, аралаша алуга ирешү.
2. Ишеткән сөйләмнең, җөмләләрнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм:**

Программада күрсәтелгән темалар буенча диалогта катнашу;
лексик тема буенча укытучының сорауларына җавап бирә һәм сораулар куя белү;
татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып, әңгәмә кору.

**Монологик сөйләм:**

Укылган өзек яисә караган рәсем буенча өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

укыган хикәядәге вакыйгаларга охшашлык буенча балаларның үзләре белән булган хәлләр турында кечкенә хикәяләр төзеп сөйләүләрен оештыру.

**Уку:**

Сәнгатьле укуга әзерләнә белү,
дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле уку,
укыган китапларның исемнәрен, авторларын хәтерләп әйтә алу.

**Язу:**

Ел дәвамында терәк сүзләр белән хикәя язу күнекмәләрен камилләштерү,
укылган өзек яки караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя язу,
бәйрәмнәр белән котлап, котлау кәгазьләре язу,
сүзлек диктантлары язу.

**Уку елы азагында белергә тиешле белемнәр:**

**Грамматик минимум:**

1. Сан, тартым белән төрләнгән исемнәргә килеш кушымчаларын ялгау тәртибен гамәли үзләштерү.
2. Зат алмашлыкларының җөмлә төзүдә куллану үзенчәлекләрен аңлату.
3. Берлек һәм күплек сандагы тартымлы исемнәрне сөйләмдә дөрес кулланугa ирешү.
4. Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр белән кулланып, җөмлә төзергз күнектерү.
5. Хикәя фигыльнең заман формаларын сөйләмдә дөрес кулланугa ирешү.
6. Билгезез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта-юклыкта зат-сан белән төрләнешен гамәли үзләштерү.
7. Буенда, буйлап, буенча бәйлек сүзләрен урынлы кулланугa ирешү.
8. Кереш сүзләрне сөйләмгә кертү.
9. Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.
10. Хикәя, боеру, сорау җөмләләрдә сүз тәртибе үзенчәлекләрен рус теле белән чагыштырып өйрәтү.

**Тыңлап аңлау:**

- 1,5 – 2 минутлык бәйләнешле текстны тыңлап, эчтәлеге буенчаукытучының сорауларына җавап бирә белү яки сөйли алу;
- Җанлы сөйләмне аңлап аралаша алу.

**Диалогик сөйләм:**

- Сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, ситуация буенча сөйләшү үткәрә алу;
- Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча әңгәмә кора алу.

**Монологик сөйләм:**

- Җыйнак җөмләләрне җәенкеләндереп, хикәя төзи алу;
- Лексик тема буенча бәйләнешле текст төзеп сөйли алу;
- Укылган текстның эчтәлеген сөйләп бирә белү.

**Уку:**

- Төрле жанрдагы текстларны сәнгатьле итеп һәм тулысынча аңлап укый һәм төп мәгълүматны таба белү;
- Тексттагы таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен сүзлекләрдән табып аңлата белү;
- Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре турында сөйли белү;
- Әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне укып, андагы вакыйгалар турында әйтеп бирә белү;
- Шигырьләрне яттан сөйли алу.

**Язу:**

- Актив үзләштерелгән сүзләрдән диктант язу;
- Лексик тема буенча хикәя яза алу;
- Укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирә алу.

| № | Тема | Камилләштерелергә һәм үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Контрольгә алынырга тиешле белем һәм күнекмәләр | Число План | Число Факт |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Лексика по теме “Мы в школе”.<br><br>“Без мәктәптә” темасында лексика. | Исәнләшү, субуллашу, хәл сорашу өчен кулланылган сүзләрне искә төшерү | | 2.09 | |
| 2 | Повторение грамматики в тексте “Сегодня первое сентября”.<br><br>“Бүген беренче сентябрь” текстындагы грамматиканы кабатлау. | Лексика белән эшләү, диалогик, монологик сөйләм төзи белү | | 9.09 | |
| 3 | Повелительное наклонение.<br><br>Боерык фигыль. | Боерык фигыльне кулланып дөрес итеп җөмләләр төзи белү, тәрҗемә итә белүне формалаштыру | | 16.09 | |
| 4 | Положительная и отрицательная форма глагола изъявительного наклонения, спряжение.<br><br>Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формасы, зат-сан белән төрләнеше. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан кушымчаларын сөйләмдә куллана белүне формалаштыру | | 23.09 | |
| 5 | Прошедшее определенное время глагола изъявительного наклонения. Я дома помощник.<br><br>Билгеле үткән заман хикәя фигыль . Мин өйдә булышчы. | Билгеле үткән заман хикәя фигыль , җөмләдә урынлы куллана белү | | 30.09 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Инфинитив.<br>Инфинитив. | Инфинитив формаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес куллана белү | | 7.10 | |
| 7 | Степени сравнения прилагательных.<br>Сыйфат дәрәҗәләре. | Сыйфат дәрәҗәләренең ясалыш үзенчәлекләрен белү, аларны урынлы кулланып җөмләләр төзи белү | | 14.10 | |
| 8 | Составление диалога по рассказу А.Бикчантаевой “Вкусное слово”.<br><br>Ә.Бикчәнтәеванын “Тәмле сүз” хикәясе буенча диалог төзү. | Яңа лексиканы үзләштерү, сөйләмдә урынлы куллану | | 21.10 | |
| 9 | Составление диалога по рассказу “Весенние каникулы”.<br><br>“Язгы каникул” хикәясе буенча диалог төзү. | Фигыльләрнең заман формаларын белү, аларны кулланып җөмләләр төзи белү | | 28.10 | |
| 10 | Этикет разговора по телефону.<br><br>Телефоннан сөйләшү этикеты. | Яңа лексиканы үзләштерү, аларны кулланып җөмләләр төзи белү | | 11.11 | |
| 11 | Лексико-грамматический материал в рассказе Ю.Еролаева “Два пирожных». Личные местоимения.<br><br>Ю.Ермолаевның “Ике пирожный”хикәясендәге лексик-грамматик материал. Зат алмашлыклары. | Яңа лексиканы куллана белү, текстның эчтәлеген аңлап тәрҗемә итә белү | | 18.11 | |
| 12 | Конструкция может работать.<br><br>Эшли ала конструкциясе. | Конструкцияне урынлы кулланып, дөрес итеп җөмләләр төзи белү | | 25.11 | |
| 13 | Научиться говорить желание работать. | Конструкцияне урынлы кулланып, дөрес итеп җөмләләр | | 2.12 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Эшләргә теләгеңне әйтә белергә өйрәнү. | төзи белү | | | |
| 14 | “День рождение – веселый праздник”.<br><br>“Туган көн-күңелле бәйрәм”. | Булышырга кирәк, чакырырга телим формаларын җөмләдән таба белү, тәрҗемәсен белү, алар белән җөмләләр төзи белү | | 9.12 | |
| 15 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Гузель у Лейсан”.<br><br>“Гүзәл Ләйсәннәрдә” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Яңа лексика белән танышу, дөрес итеп тәрҗемә итә белү, аларны кертеп җөмләләр төзи белү | | 16.12 | |
| 16 | Стол для именин.<br><br>Туган көн табыны. | Белемнәрне куллана белү, теркәгечләрне аера белү, аларны урынлы куллана белү | Тест | 23.12 | |
| 17 | Бәйлек сүзләрнең кулланылышы.<br><br>Использование предлогов. | Бәйлек сүзләрне аера белү, аларны урынлы куллана белү. Уметь правильно использовать и отличать предлоги. | | 13.01 | |
| 18 | Д.Аппакованың“Рөстәм”хикәясендәге лексик-грамматик материал. “Әдәп төбе-матур гадәт”.<br><br>Лексико-грамматический материал в рассказе Д.Аппаковой “Рустам”. Основа вежливости – красивая привычка. | Яңа лексика белән танышу, дөрес итеп тәрҗемә итә белү, аларны кертеп җөмләләр төзи белү. Ознакомление с новой лексикой, уметь правильно переводить и составлять с ними предложения. | | 20.01 | |
| 19 | Р.Вәлиеваның “Туган көндә” хикәясендәге лексик-грамматик материал.<br><br>Лексико-грамматический материал в рассказе Р.Валиева “На дне рождении” | Яңа лексика белән танышу, дөрес итеп тәрҗемә итә белү, аларны кертеп җөмләләр төзи белү. Ознакомление с новой лексикой, уметь правильно переводить и составлять с ними предложения. | | 27.01 | |
| 20 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | Тартым кушымчаларын ялгау | | 3.02 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Окончания принадлежности у существительных. | тәртибен гамәли үзләштерү.<br>Освоение порядка присоединения окончаний принадлежности. | | | |
| 21 | Яхшы уку өчен нишләргә кирәк?<br>Бәйлек сүзләр.<br><br>Что надо делать для хорошей учебы?<br>Предлоги. | Фигыльләрне кертеп җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп тәрҗемә итә белү.<br>Бәйлекләрне кулланып җөмләләр төзи белү.<br>Уметь составлять предложения с глаголами, уметь правильно переводить. Уметь составлять предложения с предлогами. | | 10.02 | |
| 22 | Инфинитив+ кирәк конструкциясе. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше | Инфинитив+ кирәк конструкциясен гамәли үзләштерү, аны кулланып җөмләләр төзи белү | | 17.02 | |
| 23 | Хикәя фигыльнең билгеле киләчәк заман формасы<br>Хикәя фигыльнең билгесез киләчәк заман формасы | Фигыльләрне кертеп җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп тәрҗемә итә белү<br>Хикәя фигыльнең заманнарын сөйләмдә дөрес итеп куллана белү | | 24.02 | |
| 24 | Инфинитив+рөхсәт итү формасы<br><br>Инфинитив + форма разрешения | Конструкцияне урынлы кулланып, дөрес итеп җөмләләр төзи белү.<br>Уметь уместно использовать конструкцию, правильно составлять с ними предложения. | | 3.03 | |
| 25 | Фигыльнең заман формалары. | Диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белү, өйрәнелгән | | 10.03 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Времена глагола. | лексиканы урынлы куллану.<br>Уметь составлять диалог и монолог, уметь правильно использовать изученную лексику. | | | |
| 26 | Хикәя фигыльнең билгесез үткән заман формасы.<br><br>Неопределенное прошедшее время глагола изъявительного наклонения. | Фигыльләрне кертеп җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп тәрҗемә итә белү.<br>Уметь составлять предложения с глаголами, правильно их переводить. | | 17.03 | |
| 27 | Инфинитив+ярата төзелмәсе.<br><br>Конструкция инфинитив + любит. | Конструкцияне урынлы кулланып, дөрес итеп җөмләләр төзи белү.<br>Уметь уместно использовать конструкцию, правильно составлять с ними предложения. | | 24.03 | |
| 28 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.<br><br>Спряжение глаголов настоящего времени изъявительного наклонения. | Фигыльләрне кертеп җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп тәрҗемә итә белү.<br>Уметь составлять предложения с глаголами, правильно их переводить. | | 7.04 | |
| 29 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.<br><br>Окончания принадлежности у существительных. | Тартым кушымчаларын ялгау тәртибен гамәли үзләштерү.<br>Практическое освоение порядка присоединения окончаний принадлежности. | | 14.04 | |
| 30 | Күрсәтү алмашлыклары. Минем сәламәтлегем.<br><br>Указательные местоимения. Мое здоровье. | Күрсәтү алмашлыкларын аера белү, аларны сөйләмдә дөрес куллана белү.<br>Уметь различать указательные | | 21.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | местоимения, правильно использовать в речи. | | | |
| 31 | Минем сәламәтлегем. Кабатлау.<br><br>Мое здоровье. Повторение. | Сыйфат фигыльләрне кертеп җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп тәрҗемә итә белү. Уметь составлять предложения с причастиями, правильно их переводить. | | 28.04 | |
| 32 | “Без спорт яратабыз” циклын кабатлау.<br><br>Повторение цикла “Мы любим спорт”. | Диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белү, өйрәнелгән лексиканы урынлы куллану. Уметь составлять диалог и монолог, уметь правильно использовать изученную лексику. | | 5.05 | |
| 33 | Татарстанда яшәүче милләтләр.<br><br>Национальности, живущие в Татарстане. | Тамырдаш сүзләрне аера белү, алар белән җөмләләр төзи белү. Уметь различать однокоренные слова, уметь составлять с ними предложения. | | 12.05 | |
| 34 | Исем ясагыч кушымчалар.<br><br>Окончания, образующие существительные. | Исем ясагыч кушымчаларны урынлы куллана белү, алар белән җөмләләр төзи белү. Уметь использовать окончания уместно, уметь составлять с ними предложения. | | 19.05 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 35 | Татарстан шәһәрләре.<br>Кебек, сыман, төсле, шикелле бәйлекләре. Татар милли уеннары белән таныштыру .<br><br>Города Татарстана. Предлог как. Ознакомление с татарскими национальными играми. | Килеш кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллана белү, дөрес итеп тәрҗемә итә белү.<br>Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне кулланып җөмләләр төзи белү, сөйләмдә куллана белү.<br>Уметь правильно использовать в речи падежные окончания. Уметь составлять предложения с предлогами и предложными словами. | | 26.05 | |

**Рус телендә сөйләшүче балаларның сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча туган (татар) теленнән белем һәм күнекмәләрен бәяләү.**

Күнекмәләрне бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

**Тыңланган текстның эчтәлеге буенча соауларга җавап бирүне бәяләү**

Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап,тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән,1 орфографик хатасы яки эчтәлеккә бәйле 1 хатасы булган эшкә “5”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеген аңлап,тәкъдим ителгән сорауларга дөрес җавап бирелгән,әмма 2-3 орфографик ,3 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 2-3 хатасы булган эшкә “4”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеген өлешчә аңлап,тәкъдим ителгән сорауларга төгәл җавап бирелмәгән,5 орфографик,5 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 4-5 хатасы булган эшкә “3”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеге буенча тәкъдим ителгән сорауларга бирелгән җавапларның яртысы дөрес булмаса,6 орфографик,6 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 5 тән артык хатасы булган эшкә”2”ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда,әйтелеше,грамматик төзелеше ягыннан дөрес,эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә,”5”ле куела. Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә,”4”ле куела. Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда,репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп,эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә,”3”ле куела. Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда “2”ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше,грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы,эзлекле монологик сөйләм өчен “5”ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән,әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә,грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хаталы монологик сөйләм өчен “4” ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән,сүзләрнең әйтелешендә,җөмлә төзелешендә 4-7 хаталы онологик сөйләм өчен “3”ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча монолог төзи алмаганда,”2”ле куела.

**Укуны бәяләү**

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап,сәнгатьле һәм аңалешлы итеп укыганда,”5”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап,сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда,әмма 2-3 орфоэпик хата булганда,”4”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда,4-6 тупас орфоэпик хата булганда,”3”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча,орфоэпик кагыйдәләрне бозып укыганда,”2”ле куела.

**Сүзлек диктанты һәм аны бәяләү** Пөхтә,төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә “5”ле куела. Пөхтә,төгәл язылган,1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булган эшкә “4” ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган,4-5 төзәтүе яки 3-5 орфографик хатасы булган эшкә”3” ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган,6 яки артыграк орографик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

| Класс | Бүлекнең ,теманың исеме | План буенча уздыру вакыты | Үзгәреш кертүнең сәбәбе | Факт буенча уздыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |